**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 03 » 12 2019 № 811

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында гаиләдә белем бирүне /үзлегеңнән белем алуны оештыру хакында Нигезләмәне раслау турында

Россия Федерациясе Гаилә кодексы, 2012 нче елның 29 нчы декабрендәге "Россия Федерациясендә мәгариф турында" 273-ФК номерлы Федераль канунның 17 һәм 63 маддәләре нигезендә гомуми белем белем бирү оешмаларында бирелергә мөмкин, шулай ук белем бирү оешмаларыннан тыш гаиләдә белем бирү һәм үзлегеңнән белем алу рәвешләрендә: башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем – гаиләдә белем бирү рәвешендә, урта гомуми белем – үзлегеңнән белем алу рәвешендә. Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып һәм Аксубай муниципаль районы территориясендә яшәүче һәм гомуми белем алу хокукына ия булган балаларны гаиләдә белем бирү/үзлегеңнән белем алу рәвешендә гомуми белем алу рәвешен сайлауны җайга салу һәм исәпкә алу зарурлыгына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1.Аксубай муниципаль районында гаиләдә белем бирүне/ үзлегеңнән белем алуны оештыру турында Нигезләмәне расларга (кушымта).

2.ТР Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесенә:

2.1.белем алырга тиешле һәм белем бирү оешмаларында белем алмаучы, шул исәптән гаиләдә белем алу рәвешен яки үзлегеннән белем алу рәвешен сайлаган балалар реестрын алып баруны тәэмин итәргә;

2.2.мондый балаларның исәбен алып баруны һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында арадаш һәм(яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен экстерн рәвештә оештырганда һәм үткәргәндә канун таләпләрен үтәүне контрольгә алырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының интернет челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый

мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Александров С.В.ка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе А.Ф.Горбунов

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты карар белән расланган кушымта
«_03_»_12_ 2019 ел, № _811_

**Аксубай муниципаль районында гаиләдә белем бирүне/үзлегеннән белем алуны оештыру турында Нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Гаиләдә белем бирү рәвешен һәм үзлегеннән белем алу рәвешен оештыру түбәндәгеләр нигезендә тормышка ашырыла:

- Россия Федерациясенең Гаилә кодексы;
- 2012 нче елның 29 нчы декабрендәге “Россия Федерациясендә мәгариф турында” 273-ФК номерлы Федераль кануны;
- Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 нче елның 22 нче гыйнварендәге "Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга гражданнарны кабул итү тәртибен раслау турында» 32 номерлы боерыгы;
- Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 нче елның 12 нче мартындагы “Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы бер оешмадан укучыларны тиешле дәрәҗәдәге һәм юнәлештәге белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы башка оешмаларга күчерү тәртибен һәм шартларын раслау турында” 177 номерлы боерыгы;
- Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 нче елның 30 нчы августындагы "Төп гомуми белем программалары - башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 105 номерлы боерыгы;
- Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 нче елның 25 нче декабрендәге “Төп гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрү тәртибен раслау турында” 1394 номерлы боерыгы;
- Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 нче елның 25 нче декабрендәге “Урта гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрү тәртибен раслау турында” 1400 номерлы боерыгы;
- Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2004 нче елның 9 нчы мартындагы “Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Россия Федерациясе мәгариф учреждениеләре өчен федераль базислы уку

планын һәм якынча уку планнарын раслау турында" 1312 номерлы боерыгы;

- Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2004 нче елның 5 нче мартындагы "Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта (тулы) гомуми белем бирүнең дәүләт белем бирү стандартларының федераль компонентын раслау турында" 1089 номерлы боерыгы;

- Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2004 нче елның 6 нчы октябрендәге "Башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартын раслау һәм гамәлгә кертү турында" 373 номерлы боерыгы;

- Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2010 нчы елның 17 нче декабрендәге "Төп гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартын раслау турында" 1897 номерлы боерыгы;

- Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 нчы елның 9 нчы гыйнварендәге "Белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыручы оешмалар тарафыннан электрон белем бирү, дистанцион белем бирү технологияләрен куллану тәртибен раслау турында" 2 номерлы боерыгы;

- Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013нче елның 15 нче ноябрендәге "Гаиләдә белем алуны оештыру турында" НТ-1139/08 номерлы хаты;

- 2013 нче елның 22 нче июлендәге "Мәгариф турында" 68-ТРК номерлы Татарстан Республикасы кануны.

1.2. Гомуми белем 2012 нче елның 29 нчы декабрендәге "Россия Федерациясендә мәгариф турында" 273-ФК номерлы Федераль канунның 17 һәм 63 маддәләре нигезендә (алга таба – Канун) белем бирү оешмаларында, шулай ук белем бирү оешмаларыннан тыш гаиләдә белем бирү һәм үзлегеннән белем алу рәвешендә: башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем – гаиләдә белеем бирү, урта гомуми белем-үзлегеннән белем алу рәвешендә алынырга мөмкин.

1.3. Гомуми белем алу формасы, белем алучы баланың фикерен исәпкә алып, балигъ булмаган укучы яки ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан билгеләнә.

1.4. Россия Федерациясе Конституциясенең 43 маддәсе нигезендә муниципаль белем бирү оешмаларында төп гомуми белемнең һәркем өчен мөмкин булуын һәм түләүсез булуын гарантияләвен исәпкә алып, ата-аналар (законлы вәкилләр), гаиләдә белем бирү/үзлегеңнән белем алу рәвешен сайлап, мәгариф оешмаларында белем алудан баш тарталар һәм гаиләдә белем бирү/үзлегеңнән белем алу вакытында барлыкка килгән йөкләмәләрне дә үз өстенә алалар.

1.5. Гаилә белеме яисә үзлегеннән белем бирү рәвешендә белем алучы зат, үзенең яисә ата-анасының (канунлы вәкилләрнең) карары буенча, укытуның теләсә кайсы этабында балигъ булмаган баланың фикерен исәпкә алып, аны канунда каралган теләсә кайсы башка формада дәвам итәргә яки белем алу рәвешләрен бергә кушарга хокуклы.

1.6. Аксубай муниципаль районы территориясендә яшәүче һәм гомуми белем алу хокукына ия булган балаларны исәпкә алу канунның 63 маддәсендәге

5 өлеше нигезендә бала яшәгән территориянең муниципаль район мәгариф бүлеге тарафыннан алып барыла.

1.7. Аксубай муниципаль районы территориясендә яшәп, белем алучы балигъ булган бала үзе яки балигъ булмаган балаларның ата-аналары (канунлы вәкилләре) гаиләдә белем бирү/үзлегеннән белем алу рәвешендә гомуми белем алу формасын сайлавын белдереп, муниципаль район мәгариф бүлегенә хәбәрнамә юллый.

1.8. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының мәгариф бүлеге белем алуның гаиләдә яки үзлегеннән белем алу рәвешен сайлап алган укучы турында мәгълүматны белем бирү оешмаларында белем алырга тиешле һәм белем алмаучы балалар реестрына кертүне тәэмин итә.

Белем алуның гаиләдә белеме бирү /үзлегеннән белем алу рәвешен сайлаган, әмма белем бирү оешмасына экстерн буларак кертелмәгән укучылар бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасында, күргәзмәләрдә, смотрларда, физкультура, спорт чараларында гаризаи тәртиптә катнашу хокукына ия. Бу очракта катнашу турында гариза муниципаль районның мәгариф бүлегенә язылa.

1.9. Татарстан Республикасының Аксубай муниципаль районы мәгариф бүлеге, әлеге территориядә яшәүче укучы белем алуның гаилә белеме/үзлегеннән белем алу рәвешен сайлап алу турында хәбәр алганнан соң, белем алучы балигъ булган балага яки балигъ булмаган баланың ата-анасына (канунлы вәкилләргә) арадаш һәм дәүләт йомгаклау аттестациясен үтәргә мөмкин булган Аксубай муниципаль районының белем бирү оешмалары турында хәбәр итә.

Балигъ булган укучының яки балигъ булмаган укучының ата-аналар (канунлы вәкилләр) теләге буенча белем бирү оешмасы гомуми белем алу чорына, конкрет аттестация үткән чорга яки бер уку елы чорына объектив шартларга карап билгеләнә ала.

Мәгариф бүлеге уку-укыту оешмасына (анда буш урыннар булганда) өстәмә аттестация һәм(яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен узу өчен укучыны мәгариф оешмасына беркетү турында мәгълүматлар җиткерә.

Балигъ булган укучы яки балигъ булмаган балаларның ата-аналары (канунлы вәкилләре) гаиләдә белем бирү яисә үзлегеннән белем алу рәвешен сайлап алынуга бәйле рәвештә мәгариф оешмасыннан чыгарылуы турындагы гариза белән бер үк вакытта арадаш һәм(яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен узу турында гариза бирергә хокуклы.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының мәгариф бүлеге ата аналар тарафыннан балигъ булмаганнарның гомуми белем алу өлешендә вазыйфаларын үтәүне тикшереп тору максатларында (44 маддәнең 4 өлешендәге 1 пункты) балигъ булмаганнар эшләре буенча Комиссиягә барлык очраклар турында хәбәр итә:

- гаиләдә белем бирү яисә үзлегеннән белем алу рәвешен сайлап алынуга бәйле рәвештә мәгариф оешмасыннан чыгарылуы һәм балигъ булган укучының яки балигъ булмаган баланың ата-аналарының (канунлы вәкилләренең) арадаш һәм(яисә) дәүләт йомгаклау аттестациясен узу өчен мәгариф оешмасына

беркетү турында мәгълүмат бирергә баш тартуы;

- экстерн кабул итү турындагы күрсәтмә актында билгеләнгән вакытта арадаш һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен узу өчен килмәве.

1.10. Кануннның 33 маддәсе нигезендә экстерннар булып арадаш һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен узу өчен белем бирү оешмасына күчерелгән затлар тора.

Экстерннар укучылар булып тора һәм укучыларга тәкъдим ителгән барлык академик хокукларга ия.

Экстерннар кирәк булганда социаль-педагогик һәм психологик ярдәм, түләүсез психологик-медик-педагогик коррекция алуга исәп тота ала.

1.11. Белем бирү оешмасы экстернга арадаш һәм(яки) дәүләт йомгаклау аттестациясе үткән вакытта бушлай дәреслекләр, белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан расланган уку предметларын укытуны тәэмин итә торган дәреслекләр һәм уку әсбаплары исемлеге нигезендә уку әсбаплары бирә.

## 2. Белем алуның гаиләдә белем бирү/үзлегеннән белем алу рәвешләрен сайлаганда белем бирү мөнәсәбәтләре барлыкка килү

2.1. Балигъ булган укучы яки балигъ булмаган баланың ата-аналары (канунлы вәкилләре) гаиләдә белем бирү яки үзлегеннән белем алу рәвеше сайлап алу белән бәйле рәвештә белем бирү оешмасына чыгару турында гариза белән мөрәҗәгать итә.

Күрсәтелгән гариза нигезендә белем бирү оешмасы өч эш көне эчендә укучының чыгарылуы турында күрсәтмә акт чыгара.

2.2. Белем бирү оешмасы балигъ булган укучыга һәм балигъ булмаган укучының ата-аналарына (канунлы вәкилләренә) баланың шәхси эшен һәм мәгариф оешмасы мөһере һәм аның җитәкчесе имзасы белән расланган укучының агымдагы уку елында өлгереше турында мәгълүмат алган документлар бирә.

2.3. Белем бирү мөнәсәбәтләре барлыкка килүгә нигез булып мәгариф оешмасының арадаш һәм(яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен узу турында күрсәтмә акты тора.

Арадаш һәм(яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен узу өчен гражданнарны кабул итү балигъ булган укучы яисә балигъ булмаган баланың ата-анасының (канунлы вәкилләренең) шәхси гаризасы буенча гамәлгә ашырыла. Белем бирү оешмасына гаризада күрсәтелгән чорга экстерн кабул итү документлар кабул ителгәннән соң 7 эш көне эчендә белем бирү оешмасының күрсәтмә акты белән рәсмиләштерелә. Белем бирү оешмасының гаризасында һәм күрсәтмә актында күрсәтелгән вакыт тәмамланганнан соң, экстерн мәгариф оешмасыннан күчерелә.

2.4. Арадаш аттестация узу турында гариза бирү сроклары, шулай ук арадаш аттестацияне узу формалары белем бирү оешмасы тарафыннан билгеләнә.

Урта гомуми белем бирү программасы буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен экстерн узу өчен гариза бирү вакыты 1 февральдән дә соңга калмыйча, төп гомуми белем бирү программасы буенча 1 марттан соң була

алмый.

2.5. Укучыны белем бирү оешмасына арадаш һәм(яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен узу өчен экстерн итеп кабул итү гамәлдәге кануннар белән мәгариф оешмаларына гражданнарны кабул итү өчен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла (Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 нче елның 22 нче гыйнварындагы “башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча гражданнарны кабул итү тәртибен раслау турында” 32 номерлы боерыгы).

2.6. Мәгариф оешмасы буш урыннар булмаган очракта гына гражданны кабул итүдән баш тартырга мөмкин. Белем бирү оешмасында урын булмаган очракта балигъ булган укучы яки балигъ булмаган баланың ата-аналары (канунлы вәкилләре) аны башка гомуми белем бирү оешмасына урнаштыру турындагы мәсьәләне хәл итү өчен турыдан-туры Татарстан Республикасы муниципаль районы мәгариф бүлегенә мөрәҗәгать итәләр.

2.7. Мәгариф оешмасында экстернның шәхси эше булмаганда арадаш һәм(яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен узган вакытка шәхси эш рәсмиләштерелә.

3. Экстерннарга арадаш һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен оештыру һәм үткәрү

3.1. Төп белем программасын гаиләдә белем бирү яки үзлегеннән белем алу рәвешендә алучылар, канунның 34 маддәсе нигезендә дәүләт аккредитациясе булган белем бирү программасы буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада экстерн рәвештә арадаш һәм(яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен узарга хокуклы.

Төп гомуми яки урта гомуми белеме булмаган әлеге затлар мәгариф оешмасында тиешле дәүләт аккредитациясе булган белем бирү программасы буенча экстерн рәвештә арадаш һәм(яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен түләүсез үтәргә хокуклы.

3.2. Мәгариф оешмасы тарафыннан арадаш аттестацияне оештыру һәм узу тәртибен, шул исәптән экстерн рәвештә, регламентлаучы тиешле локаль акт кабул ителергә тиеш. Әлеге локаль актта экстерн итеп алу турында гариза бирү вакытын, арадаш аттестациясен экстерн үткәрү вакытын, формаларын һәм тәртибен, шулай ук консультацияләр үткәргәндә дистанцион белем бирү технологияләрен куллану мөмкинлеген чагылдырырга кирәк.

Экстерн гаризасы буенча белем бирү оешмасы арадаш аттестацияне үткәрүнең шәхси вакытын билгеләргә, үзләштерелә торган белем бирү программасы кысаларында тизләтелгән укыту мөмкинлеген алдан карарга хокуклы.

Шул ук вакытта әлеге локаль акт каршылыкларсыз танышу өчен, шул исәптән Интернет челтәрендә белем бирү оешмасы сайтында да ачык булырга тиеш.

Арадаш аттестацияне үткәрү формалары һәм тәртибе мәгариф оешмасының локаль акты белән билгеләнә. Дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрү формалары һәм тәртибе мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм

норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан билгеләнә.

3.3. Гомуми белемне гаиләдә белем бирү /үзлегеңнән белем алу рәвешендә алганда, белем бирү оешмасы арадаш һәм(яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен оештыру һәм үткәрү, шулай ук укучыларның тиешле академик хокукларын тәэмин итү өчен генә җаваплы.

Ата-аналар (канунлы вәкилләр) белем, осталык һәм компетенция буенча белем алу эшчәнлеген максатчан оештыру, эшчәнлек тәҗрибәсен алу, көндәлек тормышта белем куллану тәҗрибәсен алу һәм бөтен тормыш дәвамында белем алу мотивациясен формалаштыру өчен җаваплы.

Төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен узу мәҗбүрилеге белән бәйле рәвештә экстернның ата-аналары (канунлы вәкилләре) аны гамәлдәге кануннар нигезендә узу өчен җаваплы.

3.4. Белем бирү оешмасына аттестация үтү тәртибен балигъ булган укучының яисә балигъ булмаган балаларның ата-аналарының (канунлы вәкилләренең) фикерен исәпкә алып, шул исәптән уку материалын өйрәнү темпына һәм эзлеклелегенә карап билгеләргә кирәк.

3.5. Белем бирү программасының бер яки берничә уку предметы, курс, дисциплиналары (модульләре) буенча арадаш аттестациянең канәгатьләнмәслек нәтиҗәләре яки белем бирү оешмасының күрсәтмә акты белән билгеләнгән срокта арадаш аттестациянең үтмәвенә нигезле сәбәпләр булмаганда академик бурыч дип таныла.

Балигъ булмаган экстернның ата-аналары (канунлы вәкилләре) һәм белем бирү оешмалары академик бурычны бетерү өчен шартлар тудырырга һәм аны бетерүне үз вакытында контрольдә тотарга тиеш.

3.6. Академик бурычы булган экстерннар академик бурыч барлыкка килгәннән соң бер ел эчендә тиешле уку предметы, курс, дисциплина (модуль) буенча арадаш аттестацияне белем бирү оешмасы билгеләгән вакытта ике тапкырдан да артмыйча үтәргә хокуклы. Күрсәтелгән чорга экстернның авыру вакыты, аның академик ялда яки йөклелек һәм бала табу буенча ялда булуы кертелми.

Арадаш аттестацияне икенче тапкыр үткәрү өчен мәгариф комиссия төзи.

3.7. Экстернның арадаш аттестация нәтиҗәләре беркетмәләрдә теркәлә.

3.8. Дәүләт йомгаклау аттестациясен узмаган яки дәүләт йомгаклау аттестациясендә канәгатьләнмәслек нәтиҗәләр алган экстерннар тиешле мәгариф программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрү тәртибе билгеләнгән срокларда дәүләт йомгаклау аттестациясен узарга хокуклы.

Дәүләт йомгаклау аттестациясе узмаган яки дәүләт йомгаклау аттестациясендә канәгатьләнмәслек нәтиҗәләр алган затларга үрнәк буенча белем алу яки уку чоры турында белешмә бирелә.

3.9. Арадаш аттестацияне узган һәм дәүләт йомгаклау аттестациясен узмаган экстерннарга арадаш аттестация турында белешмә бирелә.

3.10. Дәүләт йомгаклау аттестациясен узган экстерннарга, канунның 60

маддәсендәге 4 өлеше нигезендә, дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәргән мәгариф оешмасы тарафыннан төп гомуми яки урта гомуми белем турында документ бирелә.

3.11. Гаиләдә белем бирү рәвешендә башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучылар, академик бурычларын билгеләнгән вакытта бетермәгән очракта, 58 маддәнең 10 өлеше нигезендә мәгариф оешмаларында белем алуларын дәвам итәләр.

## 4. Гаиләдә белем бирү/үзлегеннән белем алу рәвешендә белем алучы укучыларның арадаш һәм(яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен оештыру һәм үткәрүне финанслар белән тәэмин итү

4.1. Мәгариф оешмасы тарафыннан гаиләдә белем бирү/үзлегеннән белем алу рәвешендә белем алучы укучыларның арадаш һәм(яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнар Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль бюджет һәм автоном белем бирү оешмаларында каралган бюджет ассигнованиеләре исәбеннән агымдагы финанслау кысаларында башкарыла.